**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

## КАРАР

«29» март 2018 Яр Чаллы шәһәре № 1077

Башкарма комитетның 2013 елның 13 ноябрендәге 5592 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны опекага (попечительлеккә) билгеләү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча административ регламентынаүзгәрешләр керту турында

РФ Хөкүмәтенең 18.05.2009 елдагы 423 номерлы Карарын (РФ Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары редакциясендә) тормышка ашыру максатларында, «Балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек алып баруның аерым мәсьәләләре турында» 1716 номерлы карары 6, 8, 10, 14, 16, 24 маддәләре нигезендә һәм «Опека һәм попечительлек турында» Федераль законның 25 маддәсе һәм Россия Федерациясе Гаилә кодексының 152 маддәсе нигезендә Тукай муниципаль Башкарма комитеты,

## КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 13 ноябрендәге 5592 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны опекага (попечительлеккә) билгеләү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 п. Закон таләпләре өлешендә медицина тикшерүе нәтиҗәләре турында бәяләмәнең бирү көненнән гамәлдә булу вакытын 6 айга үзгәртергә.

1.2. 2.6. п. Административ регламенттан яшәү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә яки торак урыныннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслаучы башка документ һәм яшәү урыныннан финанс лицевой счет күчермәләрен; Россия Федерациясе Гаилә

кодексының 146 статьясындагы 1 пунктында каралган җинаять өчен җинаять эзәрлекләвенең булмавын раслаучы Эчке эшләр органнары белешмәләрен гражданнар тарафыннан тапшыра торган документлар исемлегеннән төшереп калдырырга.

1.3. п. 3.4.1. гариза бирелгән көннән соң 2 эш көне эчендә опека һәм попечительлек органнарының гаризада күрсәтелгән белешмәләрне раслауны таләп итү бурычын билгели.

1.4. П.3.5.1. опека һәм попечительлек органы Кагыйдәләрнең 4 пунктында (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары редакциясендә) каралган мәгълүматларның тиешле вәкаләтле органнары тарафыннан расланганнан соң 3 эш көне эчендә опекун булырга теләүче затларның тормыш шартларын тикшерүне үткәрергә мәҗбүр итә, аның барышында Россия Федерациясе Граждан кодексы тарафыннан опека билгеләүгә комачаулаучы шартлар булмау билгеләнә.

1.5. п. 3.6.1. опекунны билгеләү турында карар (гражданинны опекун булырга теләгән граждан буларак исәпкә кую өчен нигез булып торган опекун булу мөмкинлеге турында карар) яисә опекун билгеләүдән баш тарту сәбәбен күрсәтеп, опека һәм попечительлек органы тарафыннан Кагыйдәләрнең 4 пунктында каралган мәгълүматларны расланган көннән 10 эш көне эчендә кабул ителә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары редакциясендә).

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасынын хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарң үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ф. Ганиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Ф. М. Камаев